**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ЮГАРЫ ЫНДЫРЧЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

21 сентябрь, 2020 ел №4

**Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Югары Ындырчы авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында 2020 елның 20 июлендәге, № 236-ФЗ Федераль законның 1 статьясындагы 1 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Югары Ындырчы авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Югары Ындырчы авыл җирлеге Советың 2018 елның 10 сентябрендәге 117 номерлы "Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Югары Ындырчы авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында" карары белән расланган "Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Югары Ындырчы авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү тәртибе турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1.6 пунктана түбәндәге эчтәлекле унберенче абзац өстәргә:

«муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы вәкаләтләре гражданнар җыены тарафыннан гамәлгә ашырыла торган җирлектә инициативалы проектларны тәкъдим итү, әзерләү, сайлап алу һәм тормышка ашыру мәсьәләләре буенча.».

2. Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга.

4.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Югары Ындырчы авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

**Югары Ындырчы авыл җирлеге**
**Башлыгы,**
**Югары Ындырчы авыл җирлеге Советы**
**Рәисе** **Ф.М. Гафиятуллин**